**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Об утверждении Положения о порядке организации экспериментов, направленных на развитие государственной гражданской службы Республики Татарстан

В соответствии со статьей 66 Федерального закона от 27 июля 2004 года № 79-ФЗ «О государственной гражданской службе Российской Федерации», статьей 44 Закона Республики Татарстан от 16 января 2003 года № 3-ЗРТ «О государственной гражданской службе Республики Татарстан» **постановляю**:

1. Утвердить прилагаемое Положение о порядке организации экспериментов, направленных на развитие государственной гражданской службы Республики Татарстан.

2. Рекомендовать органам местного самоуправления муниципальных образований Республики Татарстан руководствоваться настоящим Указом при разработке муниципальных правовых актов, определяющих порядок, условия и сроки проведения экспериментов в ходе реализации муниципальных программ развития муниципальной службы.

3. Признать утратившим силу Указ Президента Республики Татарстан от 20 августа 2014 года № УП-798 «Об утверждении Положения о порядке проведения экспериментов в рамках программ развития государственной гражданской службы Республики Татарстан».

4. Контроль за исполнением настоящего Указа возложить на Департамент государственной службы и кадров при Президенте Республики Татарстан.

5. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ

**Президент Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

Казань, Кремль
10 июня 2021 года
№ УП-475

Утверждено
Указом Президента
Республики Татарстан

от «10» июня 2021 года

№ УП-475

**Положение**
**о порядке организации экспериментов, направленных на развитие государственной гражданской службы Республики Татарстан**

1. Настоящим Положением определяются порядок организации экспериментов по применению новых подходов к организации государственной гражданской службы Республики Татарстан и обеспечению деятельности государственных гражданских служащих Республики Татарстан (далее – эксперименты), требования к проведению экспериментов в государственном органе Республики Татарстан (далее – государственный орган), его самостоятельном структурном подразделении или в территориальном органе государственного органа либо в нескольких государственных органах.

2. Эксперименты проводятся в целях:

апробации и внедрения современных технологий управления, включающих в себя новые методы планирования и финансирования деятельности государственного органа, формирования кадрового состава государственной гражданской службы Республики Татарстан (далее – государственная служба) и стимулирования профессиональной служебной деятельности государственных гражданских служащих Республики Татарстан (далее – государственные служащие);

апробации и внедрения системы показателей и критериев оценки профессиональной служебной деятельности государственных служащих;

совершенствования оплаты труда и регламентации деятельности государственных служащих;

совершенствования финансово-экономического и материально-технического обеспечения государственной службы;

оптимизации структуры и штатной численности государственного органа либо территориального органа государственного органа;

совершенствования системы подготовки и профессионального развития государственных служащих;

апробации методов осуществления кадровой работы с использованием информационно-коммуникационных технологий;

апробации дистанционной формы осуществления государственными служащими профессиональной служебной деятельности;

достижения иных целей, связанных с развитием государственной службы и повышением эффективности профессиональной служебной деятельности государственных служащих.

3. Порядок, условия и сроки проведения экспериментов, а также порядок и сроки представления итоговых отчетов об их проведении устанавливаются Президентом Республики Татарстан:

в отношении экспериментов в исполнительных органах государственной власти Республики Татарстан, их самостоятельных структурных подразделениях или в территориальных органах исполнительных органов государственной власти Республики Татарстан;

в отношении экспериментов в иных государственных органах, их самостоятельных структурных подразделениях с учетом статуса этих органов, установленного Конституцией Республики Татарстан, законами Республики Татарстан и иными нормативными правовыми актами Республики Татарстан.

4. Проект акта Президента Республики Татарстан о проведении эксперимента разрабатывается Департаментом государственной службы и кадров при Президенте Республики Татарстан в порядке, установленном законодательством Республики Татарстан, как по собственной инициативе, так и на основании предложений государственного органа, в котором планируется провести эксперимент, и должен содержать:

наименование государственного органа, его самостоятельного структурного подразделения либо территориального органа государственного органа, в которых предлагается провести эксперимент;

описание целей, задач и содержания эксперимента;

сроки проведения эксперимента;

источники финансирования эксперимента.

В случае если эксперимент предлагается провести в нескольких государственных органах, в проекте акта также указываются наименования этих органов и определяется, какой из этих государственных органов будет являться координатором эксперимента.

5. Финансирование расходов, связанных с проведением эксперимента, осуществляется за счет и в пределах бюджетных ассигнований, предусматриваемых в бюджете Республики Татарстан на содержание соответствующих государственных органов Республики Татарстан.

6. Эксперимент проводится в государственном органе (государственных органах), его самостоятельном структурном подразделении либо в территориальном органе государственного органа в соответствии с планом-графиком, утверждаемым руководителем государственного органа (руководителем государственного органа, являющегося координатором эксперимента) в 20-дневный срок со дня вступления в силу акта Президента Республики Татарстан о проведении эксперимента.

7. В плане-графике, предусмотренном пунктом 6 настоящего Положения, указываются:

сроки и форма проведения эксперимента;

этапы проведения эксперимента и ожидаемые результаты каждого из этапов;

средства контроля и обеспечения достоверности результатов эксперимента;

формы отчетности по итогам эксперимента в целом и каждого из его этапов в отдельности;

данные по кадровому, экономическому, материально-техническому и научному обеспечению эксперимента на каждом этапе;

должностное лицо, ответственное за проведение эксперимента, а также должностные лица, ответственные за проведение каждого из этапов эксперимента;

ожидаемые результаты проведения эксперимента.

8. Участие в эксперименте государственных служащих и граждан Российской Федерации, поступающих на государственную службу, осуществляется на добровольной основе.

9. На период проведения эксперимента, но не более чем на один год в порядке, установленном законодательством Российской Федерации, могут изменяться условия служебных контрактов государственных служащих – участников эксперимента.

10. Изменение на период проведения эксперимента условий служебного контракта государственного служащего – участника эксперимента осуществляется по соглашению сторон и в письменной форме. Изменение условий служебного контракта не должно приводить к уменьшению размера денежного содержания государственного служащего – участника эксперимента по сравнению с его денежным содержанием на момент начала эксперимента, а также к понижению этого государственного служащего в должности по сравнению с должностью, замещаемой им на момент начала эксперимента.

11. Ответственным за проведение эксперимента в государственном органе назначается должностное лицо, замещающее должность государственной службы не ниже заместителя руководителя государственного органа, а в случае проведения эксперимента в нескольких государственных органах ответственным за проведение эксперимента в каждом из них назначается должностное лицо, замещающее должность государственной службы не ниже заместителя руководителя государственного органа.

При проведении эксперимента в самостоятельном структурном подразделении государственного органа либо в территориальном органе государственного органа ответственным за проведение эксперимента назначается должностное лицо, замещающее должность государственной службы не ниже соответственно заместителя руководителя самостоятельного структурного подразделения государственного органа либо заместителя руководителя территориального органа государственного органа.

12. Должностное лицо, ответственное за проведение эксперимента, на основании соответствующего акта государственного органа (государственного органа, являющегося координатором эксперимента):

утверждает промежуточные планы проведения эксперимента и контролирует их исполнение;

осуществляет обеспечение необходимых организационных, методических и материальных условий проведения эксперимента.

13. Информация о ходе и результатах эксперимента размещается на официальном портале Республики Татарстан в разделе «Государственная гражданская и муниципальная служба» и на официальном сайте государственного органа, в котором проводится эксперимент (государственного органа, являющегося координатором эксперимента), в информационно-телекоммуникационной сети «Интернет».

14. Итоговый отчет о проведении эксперимента в государственном органе (государственных органах), его самостоятельном структурном подразделении либо в территориальном органе государственного органа в 30-дневный срок со дня завершения эксперимента утверждается руководителем государственного органа (руководителем государственного органа, являющегося координатором эксперимента) и направляется в Департамент государственной службы и кадров при Президенте Республики Татарстан для представления Президенту Республики Татарстан.

15. Итоговый отчет о проведении эксперимента включает в себя:

описание мероприятий, осуществленных в ходе проведения эксперимента;

сведения о достигнутых в ходе проведения эксперимента целях и решенных задачах;

сведения о возможностях, порядке и формах использования положительных результатов эксперимента в иных государственных органах и территориальных органах государственных органов;

предложения о совершенствовании нормативно-правового регулирования государственной службы по результатам эксперимента;

предложения о повышении эффективности государственной службы по результатам эксперимента;

сведения о средствах бюджета Республики Татарстан, израсходованных на проведение эксперимента.

16. Решение о целесообразности использования результатов эксперимента принимается Президентом Республики Татарстан.

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен үстерүгә юнәлтелгән экспериментларны оештыру тәртибе турында нигезләмәне раслау турында

«Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль законның 66 статьясы, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 44 статьясы нигезендә **карар бирәм:**

1. Кушымтада бирелүче Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен үстерүгә юнәлтелгән экспериментларны оештыру тәртибе турында нигезләмәне расларга.

2. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнарына муниципаль хезмәтне үстерүнең муниципаль программаларын гамәлгә ашыру барышында экспериментлар уздыру тәртибен, шартларын һәм срокларын билгеләүче муниципаль хокукый актларны эшләү барышында әлеге Указга таянырга тәкъдим итәргә.

3. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен үстерү программалары кысаларында экспериментлар уздыру тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2014 елның 20 августындагы ПУ-798 номерлы Указы үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге Указның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаментына йөкләргә.

5. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2021 ел, 10 июнь
№ ПУ-475

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Татарстан Республиксы
Президентының
2021 елның « 10 » июнендәге
ПУ- 475 номерлы Указы белән
расланды

**Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен үстерүгә юнәлтелгән экспериментларны оештыру тәртибе турында**
**нигезләмә**

1. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы дәүләт органында (алга таба – дәүләт органы), аның мөстәкыйль структур бүлекчәсендә яисә дәүләт органының территориаль органында яки берничә дәүләт органында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен оештыруда һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре эшчәнлеген тәэмин итүдә яңа алымнар куллану буенча экспериментлар (алга таба – экспериментлар) уздыру тәртибен билгели.

2. Экспериментлар түбәндәге максатларда уздырыла:

дәүләт органы эшчәнлеген планлаштыру һәм финанслауның, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең (алга таба – дәүләт хезмәте) кадрлар составын формалаштыру һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең (алга таба – дәүләт хезмәткәрләре) һөнәри эшчәнлеген стимуллаштыруның яңа ысуллары кергән заманча идарә технологияләрен сынау һәм гамәлгә кертү;

дәүләт хезмәткәрләренең һөнәри эшчәнлеген бәяләү күрсәткечләре һәм критерийлары системасын сынау һәм гамәлгә кертү;

хезмәт хакы түләүне камилләштерү һәм дәүләт хезмәткәрләре эшчәнлеген регламентлаштыру;

дәүләт хезмәтен финанс-икътисадый һәм матди-техник тәэмин итүне камилләштерү;

дәүләт органы яисә дәүләт органының территориаль органы структурасын һәм штат санын оптимальләштерү;

дәүләт хезмәткәрләрен әзерләү һәм һөнәри яктан үстерү системасын камилләштерү;

мәгълүмат-коммуникация технологияләре ярдәмендә кадрлар эшен гамәлгә ашыру ысулларын сынау;

дәүләт хезмәткәрләренең һөнәри эшчәнлеген гамәлгә ашыруның дистанцион формасын сынау;

дәүләт хезмәтен үстерү һәм дәүләт хезмәткәрләренең һөнәри эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру белән бәйле башка максатларга ирешү.

3. Экспериментларны уздыру тәртибе, шартлары һәм сроклары, шулай ук аларны уздыру турында йомгаклау хисапларын тапшыру тәртибе һәм сроклары Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан билгеләнә:

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарында, аларның мөстәкыйль структур бүлекчәләрендә яисә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының территориаль органнарында уздырылучы экспериментларга мөнәсәбәтле рәвештә;

башка дәүләт органнарында, аларның мөстәкыйль структур бүлекчәләрендә, әлеге органнарның Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасы законнары һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә билгеләнгән статусын исәпкә алып, уздырылучы экспериментларга мөнәсәбәтле рәвештә.

4. Татарстан Республикасы Президентының эксперимент уздыру турындагы акты проекты Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты тарафыннан үз инициативасы буенча, шулай ук эксперимент уздыру планлаштырыла торган дәүләт органы тәкъдимнәре нигезендә эшләнә һәм анда түбәндәге мәгълүмат булырга тиеш:

эксперимент уздырырга тәкъдим ителә торган дәүләт органы, аның мөстәкыйль структур бүлекчәсе яисә дәүләт органының территориаль органы атамасы;

экспериментның максатлары, бурычлары һәм эчтәлеге тасвирламасы;

эксперимент уздыру сроклары;

экспериментны финанслау чыганаклары.

Әгәр экспериментны берничә дәүләт органында уздырырга тәкъдим ителә икән, акт проектында шулай ук әлеге органнарның атамалары күрсәтелә һәм әлеге дәүләт органнарының кайсы экспериментның координаторы булачагы билгеләнә.

5. Эксперимент уздыруга бәйле чыгымнарны финанслау Татарстан Республикасы бюджетында Татарстан Республикасының тиешле дәүләт органнарын карап тотуга каралган бюджет ассигнованиеләре хисабыннан һәм чикләрендә гамәлгә ашырыла.

6. Эксперимент дәүләт органында (дәүләт органнарында), аның мөстәкыйль структур бүлекчәсендә яисә дәүләт органының территориаль органында дәүләт органы җитәкчесе (эксперимент координаторы булып торучы дәүләт органы җитәкчесе) тарафыннан расланган план-график нигезендә Татарстан Республикасы Президентының эксперимент уздыру турында акты үз көченә кергән көннән 20 көн эчендә уздырыла.

7. Әлеге Нигезләмәнең 6 пунктында каралган план-графикта түбәндәгеләр күрсәтелә:

эксперимент уздыру сроклары һәм формасы;

эксперимент уздыру этаплары һәм аның һәр этабыннан соң көтелә торган нәтиҗәләр;

эксперимент нәтиҗәләренең дөреслеген контрольдә тоту һәм тәэмин итү чаралары;

эксперимент нәтиҗәләре буенча тулаем һәм этапларының һәркайсы буенча аерым хисап тоту формалары;

экспериментның һәр этабын кадрлар ягыннан, икътисадый, матди-техник һәм фәнни яктан тәэмин итү буенча мәгълүматлар;

эксперимент уздыру өчен җаваплы вазыйфаи зат, шулай ук экспериментның һәр этабын уздыру өчен җаваплы вазыйфаи затлар;

экспериментны уздырудан көтелә торган нәтиҗәләр.

8. Дәүләт хезмәткәрләре һәм дәүләт хезмәтенә керүче Россия Федерациясе гражданнары экспериментта ирекле нигездә катнаша.

9. Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә эксперимент уздыру чорында, әмма бер елдан да артык булмаган вакытка экспериментта катнашучы дәүләт хезмәткәрләренең хезмәт контрактлары шартлары үзгәрергә мөмкин.

10. Эксперимент уздыру чорында экспериментта катнашучы дәүләт хезмәткәренең хезмәт контракты шартлары якларның үзара килешүе буенча һәм язма рәвештә үзгәртелә. Хезмәт контракты шартлары үзгәрүе экспериментта катнашучы дәүләт хезмәткәренең эксперимент башланган вакытка булган акчалата гомуми хезмәт хакы белән чагыштырганда акчалата гомуми хезмәт хакы күләмен киметүгә, шулай ук эксперимент башланган вакытка биләгән вазыйфасы белән чагыштырганда вазыйфасында түбәнәйтүгә китерергә тиеш түгел.

11. Дәүләт органында экспериментны уздыру өчен җаваплы итеп дәүләт органы җитәкчесе урынбасарыннан түбәнрәк булмаган дәүләт хезмәте вазыйфасын биләүче вазыйфаи зат билгеләнә, ә эксперимент берничә дәүләт органында уздырылган очракта, аларның һәрберсендә экспериментны уздыру өчен җаваплы итеп дәүләт органы җитәкчесе урынбасарыннан түбәнрәк булмаган дәүләт хезмәте вазыйфасын биләүче вазыйфаи зат билгеләнә.

Эксперимент дәүләт органының мөстәкыйль структур бүлекчәсендә яки дәүләт органының территориаль органында уздырылганда, эксперимент уздыру өчен җаваплы итеп дәүләт органының мөстәкыйль структур бүлекчәсе җитәкчесе урынбасарыннан яисә дәүләт органының территориаль органы җитәкчесе урынбасарыннан түбәнрәк булмаган дәүләт хезмәте вазыйфасын биләүче вазыйфаи зат билгеләнә.

12. Эксперимент уздыру өчен җаваплы вазыйфаи зат дәүләт органының (эксперимент координаторы булып торучы дәүләт органының) тиешле акты нигезендә:

экспериментны уздыруның арадаш планнарын раслый һәм аларның үтәлешен контрольдә тота;

эксперимент уздыруның кирәкле оештыру, методик һәм матди шартларын тәэмин итүне гамәлгә ашыра.

13. Эксперимент уздыруның барышы һәм нәтиҗәләре турында мәгълүмат Татарстан Республикасының рәсми порталындагы «Дәүләт граждан һәм муниципаль хезмәте» бүлегендә һәм эксперимент уздырылган дәүләт органының (эксперимент координаторы булып торучы дәүләт

органының) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла.

14. Дәүләт органында (дәүләт органнарында), аның мөстәкыйль структур бүлекчәсендә яисә дәүләт органының территориаль органында эксперимент уздыру турында йомгаклау хисабы эксперимент тәмамланган көннән 30 көн эчендә дәүләт органы (эксперимент координаторы булып торучы дәүләт органы) җитәкчесе тарафыннан раслана һәм Татарстан Республикасы Президентына тәкъдим итү өчен Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаментына җибәрелә.

15. Эксперимент уздыру турында йомгаклау хисабы түбәндәгеләрне үз эченә ала:

эксперимент уздыру барышында үткәрелгән чаралар тасвирламасын;

эксперимент уздыру барышында ирешелгән максатлар һәм хәл ителгән бурычлар турындагы мәгълүматларны;

башка дәүләт органнарында һәм дәүләт органнарының территориаль органнарында экспериментның уңай нәтиҗәләрен файдалану мөмкинлекләре, тәртибе һәм формалары турындагы мәгълүматларны;

эксперимент нәтиҗәләре буенча дәүләт хезмәтен норматив-хокукый җайга салуны камилләштерү турында тәкъдимнәрне;

эксперимент нәтиҗәләре буенча дәүләт хезмәтенең нәтиҗәлелеген арттыру турында тәкъдимнәрне;

эксперимент уздыруга сарыф ителгән Татарстан Республикасы бюджеты акчалары турында мәгълүматларны.

16. Эксперимент нәтиҗәләрен куллануның максатка ярашлылыгы турында карар Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан кабул ителә.

---